**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Олыяз авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2022 елның 10 ноябре** **№ 3**

**Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Түбән Казаклар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 25 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Түбән Казаклар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Түбән Казаклар авылы, М. Җәлил урамы, 18 йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге Түбән Казаклар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Түбән Казаклар авылы юлларында чокырларны ремонтлау, вак таш җәю һәм асфальт җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Түбән Казаклар авылына энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу;
- зиратны карап тоту өчен инвентарь сатып алу (вата торган чүкеч, кабер казу өчен җир боравы; бензин пычкысы – штиль һәм чылбыр; чапкычлар (триммер) , агач материаллары ) килешү буенча түләү; смета документларын төзү;
- Түбән Казаклар авылы яр буе зонасын төзекләндерү һәм карап тоту (кыргый үскән куакларны, агачларны кисү, төпләү, чүп-чар чыгару, ягулык-майлау материаллары сатып алу, бульдозер, экскаватор эше, ком белән тигезләү, вак аш салу), смета документларын төзү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Түбән Казаклар авылындагы урам юл челтәрен карап тоту (килешү буенча)?

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Гражданнар җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Олыяз авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Олыяз авыл җирлеге башлыгы Р. Ф. Маликов